КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 февраль г.Казань № 89

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына конкурста катнашуга гариза формасын раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының $35^{1.1}$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына конкурста катнашуга гариза формасын раслау турында
2. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
20210 ел, 19 февраль, 89 нчы
карары белән расланды

Форма

Оешманың бланкы (булган очракта)

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына конкурста катнашуга гариза

___________________________________________________ (алга таба - мөрәҗәгать итүче)
(мөрәҗәгать итүченең тулы рәсми исеме)

| | |
|---|---|
| Мөрәҗәгать итүченең адресы | |
| Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| Банк реквизитлары | |
| Контакт телефоны номеры | |

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына конкурс турындагы документацияне өйрәнгәннән соң, файдалану хокукына конкурста катнашу теләге турында хәбәр итә ______________________________________.
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

Мөрәҗәгать итүче конкурста катнашу таләпләрен һичшиксез үтәү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы билгеләгән тәртиптә һәм шартлар нигезендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына конкурс уздыру шартлары нигезендә йөкләмәләрне үз өстенә ала.

Мөрәҗәгать итүче конкурс турындагы документларда күрсәтелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануның төп шартлары белән ризалыгын белдерә һәм аны конкурста җиңүче дип таныган очракта аларны җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия составына кертүгә килештерә.

______________________ ______________________ ______________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы) (мөрәҗәгать итүче имзасы) (дата)

М.У.
(булганда) ______________ ________________ _________________

____________________________